ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2024 ел Баулы шәһәре №68

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 120 номерлы карары белән расланган, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү буенча һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру тәмамланганы турында Актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 120 номерлы (2023 елның 27 июлендәге 157 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары белән расланган, күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү буенча һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру тәмамланганы турында Актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлектә «Гомуми нигезләмәләр»:

1.5. пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп планлаштыру үз эченә ала: әлеге бинаның чикләрен һәм (яки) мәйданын үзгәртү, һәм (яки) яңа биналар барлыкккa китерү, шул исәптән Россия Федерациясе торак кодексының 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яки) аның эчке планнировкасын үзгәртү (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яки) мәйданын үзгәртмичә). Бинаны планлаштыруны үзгәртү нәтиҗәсендә шулай ук аның

чикләре һәм (яки) чиктәш биналарның мәйданы үзгәрергә мөмкин. Үзгәртеп планлаштыру күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына бинаның (биналарның) чикләре һәм (яки) мәйданы турында үзгәрешләр кертү яки барлыкка китерелгән биналарның дәүләт кадастр исәбен һәм барлыкка китерелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыру кирәклегенә китерә;»;

3 бүлектә «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлеш вакыты, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, гомуми билгеләр белән берләшкән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү тәртибен үз эченә ала, шул исәптән алар алган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә карата»:

3.10. бүлекчә белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга :

«3.10. Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны тәмамлау

Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру тәмамлангач, мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Торак кодексының 23 статьясының 9 өлешендә каралган ысул белән бүлеккә күрсәтелгән эшләрнең тәмамлануы турында хәбәрнамә җибәрә. Бинаны үзгәртеп планлаштыру очрагында мондый хәбәрнамәгә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән, үзгәртеп планлаштырылган бинаның техник планы кушыла. Бинаны үзгәртеп планлаштыру нәтиҗәсендә яңа биналар барлыкка килгән очракта, бинаны үзгәртеп планлаштыру тәмамлану турындагы хәбәрнамәдә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашырган өчен дәүләт пошлинасы түләнүе турында мәгълүмат күрсәтелә.

Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру кабул итү комиссиясе акты белән раслана, аны раслау әлеге пунктның беренче абзацында каралган хәбәрнамәне, биналарны күчерүне гамәлгә ашыручы Бүлек алганнан соң утыз көннән дә артмаган вакыт эчендә башкарыла.

Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору әлеге пунктның икенче абзацында каралган акт расланган көннән тәмамланган дип санала. Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп планлаштыру бинаның чикләре һәм (яки) мәйданы турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына үзгәрешләр кертелгәннән соң яки оешкан биналарның

дәүләт кадастр исәбен һәм оешкан биналарга хокукны дәүләт теркәвен гамәлгә ашырганнан соң тәмамланган дип санала.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы

И.И. Хөснуллина